Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Шәһәр тибындагы
Совет поселогы
423060, Аксубай штп,
Советлар урамы, 2 нче йорт
т.2-73-62

Совет поселка городского типа
Аксубаево
Аксубаевского муниципального района
Республики Татарстан
423060, пгт Аксубаево,
ул.Советская, д.2
т. 2-73-62

# КАРАР

№ 94 19 сентябрь 2024 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» Советының 2011 елның 25 февралендәге 5 номерлы «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы территориясендә күзәтүчесез хайваннарны аулау тәртибе һәм йорт хайваннарын тоту кагыйдәләре турында " карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм хайваннар белән җаваплы эш итү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль Законда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Аксубай шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР КЫЛДЫ::

1. Аксубай муниципаль районының «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» Советының «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы территориясендә күзәтүчесез хайваннарны аулау тәртибе һәм йорт хайваннарын тоту кагыйдәләре турында» 2011 елның 25 февралендәге 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Карар исемен яңа редакциядә бәян итәргә: «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы территориясендә күзәтүчесез хайваннарны тоту тәртибе турында".

1. 2. Аксубай штп Советының 25.02.2011 елгы 5 номерлы карарының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга. 1.3 Аксубай штп Советының 25.02.2011 ел, № 5 карарының «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы территориясендә йорт хайваннарын тоту кагыйдәләре» 1 нче кушымтасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubayevo.tatar.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru".

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Аксубай шәһәр тибындагы
поселогы башлыгы урынбасары Бакиров А.М.